РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА НОВОТУМБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНА ТУМБА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Яңа Тумба ав. КАРАР

«2» ноябрь 2020 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлегенең Яңа Тумба авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Шоссе урамы буенча 4нче йорт адресы буенча урнашкан киберт бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Совет, Пушкин, Михайлов, Урманчылар, Лежнивая, Новая урамнарындагы йортларда яшәүче гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Садовая урамы буенча 4нче йорт адресы буенча урнашкан почта бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Завод, Липовая, Садовая, Хастаханә, Дорожная, Речная, Полевая, Луговая, Лесная, Хастаханә тыкрыгы урамнарындагы йортларда яшәүче гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Яңа Тумба авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу;

- Яңа Тумба авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау.

«Әйе» «Юк»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Осипов